ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 9 Иске Урыссу авылы 2020 елның 22 июле

2014 елның 21 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге советының «Физик затлар милкенә салым турында»гы 24 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры килүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Ютазы районы прокуратурасының 2020 елның 30 июнендәге 02-08-01 санлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. 2014 елның 21 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында»гы 24 санлы карарына (30.11.2018 ел, № 26 редакциясендә) түбәндәге үзгәреш кертергә:

   3.1 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

   «Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы» .
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап, Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru, муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб - адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында.
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Ф.Г. Әминова